**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№ 115 26.10.2018 ел

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»**
**2014 елның 17 ноябрендәге 139 номерлы**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль**
**районы Югары Налим авыл җирлеге**
**Советы карарына үзгәрешләр кертү**
**хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 32 бүлеге нигезендә, шулай ук «Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 139 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 178 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
 1.1. 2 пунктта:
  а) 2 пунктта «фатирларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә;
  б) 3 пунктта «торак йортларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә.
 1.2. 3 пунктчада «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел.
3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Ф.Н. Николаева**